РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь 2023г. г. Альметьевск № 245

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 20 апрелендәге 141 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм тезелеш кагыйдәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр тезелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2023 елның 28 гыйнварындагы 63 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда генераль планнарга һәм җирдән файдалану кагыйдәләренә һәм төзелешкә җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрмичә үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» карары, «Татарстан Республикасында шәһәр тезелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 06 апрелендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 6 пункты, Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 11 декабрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлегенең генераль планы турында» карары белән

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 20 апрелендәге 141 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм тезелеш кагыйдәләре турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 12 декабрендәге 181 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 227 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

- 1 статьяның 35 абзацында «, шәһәр округы яисә муниципаль районның авылара территориясе» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 14 статьяның 4 елешендәге «а» пунктында «, шәһәр округы, муниципаль районның авылара территориясе» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 19 статьяның 2 елешендәге 1.1 пунктында «, шәһәр округы, авылара территория» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 30 статьяның 30.1 елешендәге 3 пунктында «, шәһәр округлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренең 2022 елның 20 апрелендәге кушымтасында:

- П2 (П2-Ф) зонасы регламенты нигезендә җирләрдән фактта файдалану территориясе шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында (Рус Акташы авыл җирлегенең көньяк елешендә) 16:07-7.17 реестр номеры белән «III класслы хәвефлелекнең җитештерү һәм склад объектлары зонасы (П2) №3-2» территориаль зонасына алмаштырырга;

| Гамәлдәге хәл | Проект үзгәрешләре |
| --- | --- |
|  |  |

- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында (территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар) П2 (П2-Ф) зонасы регламенты нигезендә җирләрдән фактта файдалану территориясе (Рус Акташы авыл җирлегенең кеньяк өлешендә) 16:07-7.17 реестр номеры белән «III класслы куркыныч производство һәм склад объектлары зонасы (П2) №3-2» территориаль зонасына алмаштырырга.

| Гамәлдәге хәл | Проект үзгәрешләре |
| --- | --- |
|  |  |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары М.Н.Гирфановка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов